РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

**№ 39/4** **2018 елның 23 ноябре**

***Решение*** ***Карар***

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру хакында

Чистай муниципаль районы Советы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары нигезендә Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проекты буенча 2018 елның 10 декабренә 14-00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц-залында түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар уздыруны билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.
2. Фикер алыша торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча язма рәвештә җибәрелә: Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт, 19 нчы каб., 5-43-70 факсы буенча яисә электрон почта адресына - chistay@tatar.ru ачык тыңлаулар уздырганчы. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр (төшке аш 12-00 дән 13-00 сәгатькә кадәр) кабул ителә.
3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай

муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» (алга таба - оештыру комитеты) түбәндәге составта карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә:

Иванов К.В. - Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары;

Карманова Н.А. - Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;

Хаматов Р.Г. - Данауровка авыл җирлегеннән депутат, Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Осипов Г.Н. - Түбән Кондрата авыл җирлегеннән депутат, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Садриева И.Ш. - Чистай муниципаль районы Советы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы;

Абзалова Л.Н. - Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы;

Белова-Реутина В.Н. - Чистай муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе.

4. Йөкләргә:

- оештыру комитетына ачык тыңлаулар үткәрүне, күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы утырышына проектны кертергә.

5. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны һәм Чистай муниципаль районы Советының «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы карары проектын билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары К.В. Ивановка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов